1990 елның
1 гыйнварыннан
чыга

№ 16 (2944)
Пәнҗешәмбе
23 апрель,
2026 ел

«И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!»

# Туган як

12+
Октябрьский шәһәренең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни басмасы

26016
4 665299 182002

«Яшел Башкортстан» акциясе кысаларында Октябрьскийда 830 агач утыртылды / 2 бит



Төзекләндерү, көнкүреш мәсьәләләре буенча бистә халкы беренче чиратта кемгә шалтырата? / 3 бит

26 апрель – халык шагыйре, милләтебезнең бөек шәхесе – Габдулла Тукай туган көн / 5 бит

# Ял урыны матурлана

*Губкин исемендәге скверда барган үзгәрешләрне шәһәр халкы инде бүгеннән үк сизә*



Автор фотолары

Төзекләндерү

**Гүзәл НАСЫЙБУЛЛИНА**

***«Тормыш өчен инфраструктура» милли проекты кысаларында «Уңайлы шәһәр мохитен булдыру» федераль программасы буенча шәһәрдә берничә объект төзекләндерелә. Шуларның берсе — Губкин исемендәге сквер.***

Биредә төзекләндерү эшләре тулы куәтенә бара. Иске плитәләр һәм бордюрлар инде сүтеп алынган. Һәйкәлне урнаштыру өчен яңа, ышанычлы нигез әзерләнгән. Без барганда, дистәгә якын кеше брусчатка өчен аслык әзерли, яңа бордюрлар урнаштыра, кайберләре электр яктырткычлары өчен тимерчыбык суза иде. Эшчеләрнең күңелле ыгы-зыгысы, техника тавышы — барысы да скверның тиздән яңа сулыш алачагын искәртә.

Булачак ял урынының проекты чыннан да сокландыргыч. Паспорт буенча, скверда ап-ак плитка түшәлгән җәяүлеләр юлы, уртада — чәчәк клумбасы, ян якларда — утыргычлар. Алга таба скверда урам сәгате урнаштырылачак, ә Губкин бюсты үз урынына кайтарылачак. Шулай ук, әлегә каплап куелган фонтан да шәһәр халкын сөендереп, эшләп торыр дип көтелә.

Әлеге үзгәрешләргә карата шәһәрдәшләрнең фикерләрен дә белдек.

«Элек Губкин истәлегенә куелган бюстның плитәләре купкан иде. Яңарту эшләреннән соң күзгә күренеп матурланыр, яңа сулыш керер дип көтәм. Балалар белән йөрергә, эскәмиядә утырып ял итәргә менә дигән урын булыр», — дип сөенә биредә яшәүче Гөлнара ханым.



«Шәһәр үзәгендә шундый ял урыны булдыру — бик кирәкле эш», — дип өстәде пенсионер Рәшит абый.

Губкин исемендәге сквер тиздән шәһәрнең иң матур һәм яраткан ял урыннарының берсенә әверелер. Биредә гаиләләр, балалар, өлкәннәр үзләренә ямь табар, ял итәр, аралашыр. Бу — «Уңайлы шәһәр мохите» программасының уңышлы гамәлгә ашуының ачык мисалы.

Атна хәбәрләре

## Язылырга ашыгыгыз!

**29 апрельгә кадәр гәзиткә ташлама белән язылу мөмкинлеген кулдан ычкындырмагыз!**

Әгәр редакциягә килә алмасагыз, абунәне телефон аша рәсмиләштереп була: 6-00-03, 6-03-28 яки 8 (927) 322-92-56.

Социаль реклама

## Алинәнең зур уңышлары

**Октябрьскийдан Алинә Зиннәтуллина Казанда узган ике абруйлы чарада яхшы нәтиҗәләргә иреште.**

9нчы мәктәп укучысы XIII Халыкара татар теле һәм әдәбияты олимпиадасында шәһәр абруен лаеклы яклап, призер булды. Укытучы-остазы —Гөлназ Гәрәева. 13-16 апрельдә үткән белем ярышында 5 чит илдән һәм Русиянең 30 төбәгеннән 500 укучы катнашты.

16 апрельдә шулай ук бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга багышланган Бөтенрусия туган тел форумында аның әсәрләре һәм иҗаты буенча рәсем конкурсы җиңүчеләрен бүләкләделәр. Иҗади ярышта Алинә иң яхшылар арасында булып, икенче урын яулады.

## Иң яхшысы — бездә

**Бөтенрусия смотр-бәйгесе нәтиҗәләре буенча шәһәр «Юнармия йорты» җиңүче дип танылды.**

Финалда илнең төрле төбәкләреннән 28 учреждение көч сынашты. Катнашучылар үз проектларын яклап, иң яхшы тәҗрибәләрне һәм эш нәтиҗәләрен күрсәтте. Конкурста җиңү заманча җиһазлар алу мөмкинлеген бирә. Бу яшь буынны укыту һәм тәрбияләү шартларын яхшыртырга ярдәм итәчәк.

## Майда ничек ял итәбез?

**Быел ял көннәре Яңа ел каникулларыннан күчерелмәгән, шуңа күрә май бәйрәмнәре кыскарган.**

Беренче ял көннәре 1-3 майда — җомгадан якшәмбегә кадәр дәвам итә. Икенче өлеше 9-11 майда — шимбәдән дүшәмбегә кадәр була. 30 апрель һәм 8 май — кыскартылган эш көне. Шулай ук, 27 май Корбан бәйрәме хөрмәтенә ял көне була.

vk.com/tuganyak1990

t.me/tuganyak1990

https://okt-tuganyak.ru/

**һава торышы**
24 - 26 апрель
gismeteo.ru

| 24 апрель җомга | 25 апрель шимбә | 26 апрель якшәмбе |
|---|---|---|
| +6°С +13°С | +3°С +8°С | +7°С +12°С |